| Республика Татарстан | | Татарстан Республикасы |
| --- | --- | --- |
| Исполнительный комитет Менделеевского муниципального района | | Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

28.06.2024 Менделеевск ш. № 404

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының һәм Менделеевск шәһәренең социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарын наем шартнамәләре буенча торак урыннарыннан файдаланган өчен түләү күләмен исәпләү турында

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2016 елның 27 сентябрендәге 668/пр номерлы боерыгы белән расланган Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарын наем шартнамәләре буенча торак урыннарыннан файдаланган өчен түләү күләмен билгеләүнең методик күрсәтмәләренә үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының һәм Менделеевск шәһәренең социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарын наем шартнамәләре буенча торак урыннарыннан файдаланган өчен түләү күләмен кушымта нигезендә 2024 елның 1 июленнән расларга.
2. “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының һәм Менделеевск шәһәренең социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарын наем шартнамәләре буенча торак урыннарыннан файдаланган өчен түләү күләмен раслау турында” Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комиетының 2020 елның 18 мартындагы 201 номерлы крарарының 2 пункты 2024 елның 1 июленнән үз көчен югалткан дип санарга.
3. Карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында “Норматив документлар " бүлегендә урнаштырырга www.mendeleevsk.tatarstan.ru

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы һәм инфраструктура үсеше һәм торак сәясәте буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Искәндәров

КИЛЕШЕНГӘН:

Башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасары А.Ф.Искаков

Башкарма комитетның юридик бүлек башлыгы Е.С.Царева

Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның ______________
карарына кушымта

2024 елның 1 июленнән Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының һәм Менделеевск шәһәренең социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарын наем шартнамәләре буенча торак урыннарыннан файдаланган өчен түләү күләме

2020 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы дәүләт һәм муниципаль торак фондының торак урыныннан файдаланган өчен (аренда өчен түләү) база күләме.

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы дәүләт һәм муниципаль торак фондының торак урыныннан файдаланган өчен түләү күләмен (аренда өчен түләү) исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәгә ярашлы рәвештә, торак урыныннан файдаланган өчен түләүнең база күләме (аренда өчен түләү) биләгән гомуми мәйданның 1 квадрат метры өчен формула буенча билгеләнә:

НБ = СРс * 0,001,

НБ- торак бинаны арендага алу өчен түләүнең төп күләме;

СРс - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районындагы икенчел торак базарында социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннарны наем шартнамәләре буенча бирелә торган дәүләт һәм муниципаль торак фондының торак урыны урнашкан 1 кв. м уртача бәя социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучыларга торак урыннан файдаланган өчен түләү күләмен билгеләү методик күрсәтмәләрнең 3.2 пункты нигезендә Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2016 елның 27 сентябрендәге 668 номерлы боерыгы белән расланган Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең актуаль күрсәткечләре буенча билгеләнә.